Кукмара муниципаль районы
Кукмара шәһәре Советы
карары

18 февраль 2019 ел №4

Кукмара поселок Советының 2014нче елның 15нче мартында 06нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының штп. Кукмара муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) йөкләмәләрен үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны күчерү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2018нче елның 30нчы октябрендәге 387- ФЗ номерлы "Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законның 2нче һәм 28нче матдәләренә үзгәрешләр кертү хакындагы" Федераль закон белән тәңгәлләштерү максатыннан Кукмара шәһәре Советы карар итте:

1.Кукмара поселок Советының 2014нче елның 15нче мартында 06нчы номерлы карары (2016нчы елның 19нчы апрелендә 9нчы номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының штп. Кукмара муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәле яки хезмәт (вазыйфаи) йөкләмәләрен үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны күчерү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Карар белән Нигезләмәнең исемнәрендә һәм текстлары буенча "Кукмара ш.т.п." сүзен "Кукмара ш." сүзе белән алмаштырырга;

2) 2 нче пунктның икенче абзацында "хәлиткеч тавыш хокукы белән" сүзләрен "комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д.Димитриев